Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Важашур авыл җирлеге Советы

КАРАР

14 март 2025 ел №3

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы Важашур авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр
кертү проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Важашур авыл җирлеге советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Важашур авыл җирлеге Советы Карары проектын (1 нче кушымта) хупларга.

2. Важашур авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча, Важашур авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 28.01.2020 ел, №4 карары нигезендә гавами тыңлаулар үткәрергә. ".

3. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Важашур авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Иванов Петр Леонидович - комиссия рәисе;

Кузнецова Анжелла Андреевна - комиссия члены;

Гильманова Альбина Анатольевна - комиссия члены.

5. Билгеләргә:

5.1. Гавами тыңлауларны уздыру датасы – 07.04.2025 ел.

5.2. Гавами тыңлауларны үткәрү вакыты - 17.00 сәгать.

5.3. Үткәрү урыны-Починок Сутер МФЦ бинасы, адресы: ТР, Кукмара районы, Починок Сутер авылы, Яшьләр ур., 1д йорт.

6. Эшче төркемгә гавами тыңлауларда кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге Советы утырышы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: httrs://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән http://kukmor.tatar.ru

Җирлек башлыгы: П.Л. Иванов

ОГРН 1021607762778
ИНН 1623001734

Проект

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Важашур авыл җирлеге Советы

КАРАР

______________ 2025 ел. №____

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Важашур авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атамасы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге, кыскартылган атамасы – Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге (текстта алга таба – җирлек).».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы: П.Л. Иванов

Важашур авыл җирлеге Советының
2025 елның 14 мартында кабул ителгән
3 нче номерлы карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Важашур авыл җирлеге Советы Карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында " карар проектына тәкъдимнәр Важашур авыл җирлеге советына түбәндәге адрес буенча кертелә: ТР, Кукмара районы, Починок Сутер авылы, Яшьләр ур., 1д йорт, яисә (84364) 36239 факсы буенча язма рәвештә кушымтада бирелә торган үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| Тәртип номеры | Статья, пункт, подпункт | Карарның проект тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәләрне искә алып проектның тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.О., адрес, телефон, эш (уку) урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр карар игълан ителгән көннән алып бер ай эчендә эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар шәхсән яисә почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: ТР, Кукмара районы, Починок Сутер авылы, Яшьләр урам, 1д йорт (конвертта "Устав турында фикер алышу" яисә "гавами тыңлаулар" тамгасы белән), шулай ук (84364) 36239 факсы буенча.

Гаризалар эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр, гавами тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Важашур авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге башлыгы урынбасарына тапшырыла.

Җирлек башлыгы: П.Л. Иванов